**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ АЕШ АВЫЛ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**423741, Аеш авылы,**
**Ленин ур.,34б нче йорт.**
**Тел/факс 3-44-41**
**e–mail: aish-akt.galeeva@yandex.ru**

**АИШЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423741, село Аишево,**
**ул.Ленина, дом 34б.**
**Тел/факс 3-44-41**
**e–mail: aish-akt.galeeva@yandex.ru**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«24»февраль2025 ел №5/1

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Актаныш муниципаль районының Аеш авылы җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Актаныш муниципаль районының “Аеш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 маддәсе, Аеш авыл җирлеге башлыгы:

Карар бирэ:

1. 2025 елның 05 мартында 15 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районының Аеш авыл җирлегенең Аеш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы 04.12.2024 ел, №22 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлегенең Аеш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 04.12.2024 ел, №22 карарга, карарның 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертү белән килешәсезме:

"Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 245 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 125 граждан кертелде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Риза» позициясе өчен 125 граждан тавыш бирде;

«Каршы " позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

«Тыелып калдылар» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Аеш авылы, Ленин урамы, 34б

4. Актаныш муниципаль районының Аеш авыл башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, Аеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Д.Р.Ахатов